# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Зур Тигәнәле авылы

23 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Зур Тигәнәле торак пунктында гражданнар җыены

**карар итте**:

1.2021 елда Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- Зур Тигәнәле авылында авыл эчендәге юлларга таш җәю, төзекләндерү һәм карап тотуны хәл итү.

3.Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 нче йорт.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы С.Җ.Әхмәтҗанов